СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №59 (7232) | 23 май, 1991 ел. ПӘНҖЕШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.



Елмайган күзләре белән төбәлгән уйчан йөзле бу егет—Мамык авылы механизаторы И. Колотилин. Әле ул яшь кенә булуына карамастан, 10 ел эшләү дәверендә тәҗрибәле тракторчы булуга иреште. Иван—«Сөлчә» совхозында иң алдынгы механизаторларның берсе. Узган елда ул үзенә бирелгән йөкләмәне 115 процентка арттырып үтәгән иде, быелгы чәчүдә дә сынатмады.

Рәсемдә: «Сөлчә» совхозы тракторчысы И. Г. Колотилин.

## БЕЗНЕҢ ФИКЕРЛӘР

### Риза түгел

Татарстан республикасының халык депутаты Фәүзия Бәйрәмованың сәяси ачлык игълан итүен телевизордан карап белдем. Шундый кызу май көнендә кояш астында утыруы аңа җиңел түгелдер. Ләкин ни хәл итмәк кирәк, депутат моны азатлык хакына эшли. Әйе, Татарстанда РСФСР Президенты сайланырга тиеш түгел дигән фикерне мин дә хуплыйм. Минем дә күңелдә шик яши: шул рәвешчә Татарстанда Россия Президенты сайланылса, бу безнең мөстәкыйльлеккә ирешү юнәлешендәге хәрәкәтләребезне юкка чыгара: азатлыкка шул урында нокта куела. Без моңа риза түгел. Җитәр, болай да еллар буена телебезне кысып килделәр, милли үсешебезне чикләделәр. Ә бит безнең дә союздаш республикалар белән тигез хокуклы буласы килә.

Әйе, азатлыкны чыннан да җиңел генә, бәхәс, көрәшсез яулап булмый. Ә көрәш өчен Ф. Бәйрәмова шикелле депутатлар кирәк тә.

**З. ИСХАКОВА.**
Норлат шәһәре.

### Һәркемнең шәхси эше

12 июньдә ТССР һәм РСФСР Президентларын сайлау үтәчәге турында халык арасында аңлату эшләрен башлап җибәрдек. Бездә төрле милләт кешеләре яши, аларның моңа карашлары да төрлечә. Сер түгел, сайлаудан туйганлыкларын белдерүчеләр, бердән дәүләттә бер генә—союз президенты гына булырга тиешлеген яклаучылар, бу эш белән шөгыльләнгәнче халыкны тәэмин итүгә игътибар арттыруның зарурлыгына басым ясаучылар да бар.

Болар, аерып күрсәтсәм дә, хәлиткеч фикерләр түгел, аерым кешеләргә хас. Тулаем алганда, татары, русы, чувашы, мордвасы җөмһүрияткә президент кирәклеген, аны сайлауда катнашачагын белдерә. Союз составында тулы хокуклы дәүләт булып яшәргә омтылабыз икән, аның инде закон нигезендә сайланган башлыгы да булырга тиеш. Халык әйтмешли, без кемнән ким?! Башкалар белән тигез булгач, алардагы тәртиптә бездә дә җитәкче булырга тиеш.

Мәгълүм булганча, Югары Совет РСФСР Президентын сайлауда да катнашу турында карар кабул итте. Бу мәсьәләдә минем позиция мондый: дөрес эшләнде әлеге алым. Нигә дисәң, безнең җөмһүрияттә төрле милләт вәкилләре яши. Аларның бу мәсьәләгә фикерен, карашын, алда әйткәнемчә, безнең Заречный поселогы мисалында да аңлап була. Авылдашлар арасында төрле кешеләр, шул исәптән РСФСР Президентын сайлауны яклап чыгучылар бар. Бу сайлауда катнашмау әнә шундый кешеләрне тавыш бирү хокукыннан мәхрүм итү булыр иде. Теләгәннәр катнашсын, теләмәгәнен берәү дә көчләми—ихтыяры, һәркемгә вөҗдан иреге. Ә тулаем алганда исә, Югары Совет билгеләп үткәнчә, карарның безнең җөмһүрият өчен юридик көче булмаячак.

**М. СТАҖАРОВА,**
халык депутатларының Заречный авыл Советы рәисе.

### БЕЗ КАРШЫ

Газетаның 13 май санында ТССР халык депутаты А. Н. Ежов белән әңгәмәне укыгач, бездә бу уңайдан үз фикеребезне белдерү теләге уянды. Дөресен әйтик, безгә депутатның Татарстан республикасында РСФСР президентын сайлауны үткәрүне яклавы бер дә ошамады. Бу чын мәгънәсендә безнең Декларациягә каршы килә бит.

Алайга китсә, Татарстан Президентын сайлауга Үзбәкстан һәм башка республикалардагы милләттәшләребез дә катнашырга тиеш, чөнки татарлар яшәмәгән республика гомумән юк бит. Әмма ни сәбәптәндер, урыслар сорый дип Әрмәнстанда яки башка җирдә РСФСР Президентын сайламыйлар. Бездә генә гел шулай: бер-ике кеше тел тибрәтсә, халык сорый дип, безнең өчен кемнәрдер хәл итә дә куя. Без моңа гаиләбез белән каршы.

**Сөләймановлар гаиләсе.**
Норлат шәһәре.

## Мөстәкыйльлегебез өчен тавыш бирәбез

### Татарстан Президенты постына кандидатлар күрсәтү җыелышлары башланды

**Татарстанның сәяси тормышы кыза бара. Ай да үтмәс—татар тарихында беренче мәртәбә Президентка сайлаулар булыр. Төрле партияләр, иҗтимагый хәрәкәтләр каударланып кандидатура эзли, җыелышып бәхәсләшә.**

«Казан» кошчылык фабрикасы коллективы да бу вакыйгадан читтә калмады. Монда эшчеләрнең гомуми җыелышында, (анда 700ләп эшченең яртысы чамасы катнашты) мөстәкыйль Татарстанның беренче Президенты постына кандидат итеп МИНТИМЕР ШӘРИПОВИЧ ШӘЙМИЕВне тәкъдим иттеләр. Җыелышны алып барган фабрика директоры Фәһим Фәхруллин кыска гына чыгышында республикадагы икътисади һәм сәяси хәл турында сөйләде. Бөтен союзда һәм Россиянең төрле почмакларында милли каршылык кискенләшкән, шахта һәм заводлар забастовкалардан тетрәп торган бер чорда Татарстаныбыз сабыр гына иҗтиһат итә, азык-төлек белән тәэмин итү чагыштырмача начар түгел, диде ул. Монда инде, һичшиксез, хәзерге катлаулы чорда Татарстан Республикасы Югары Советын җитәкләүче М. Шәймиевнең шәхси өлеше зур.

Кошчылар күрсәтелгән кандидатны бертавыштан якладылар. Хәтта безнең плюрализм заманасы өчен гайре табигый кебек булып китте...

Кайбер эшчеләрдән М. Шәймиевне ни өчен яклауларын һәм Президентны нинди итеп күрергә теләүләрен сорадым.

КӘҮСӘРИЯ ГАНИЕВА, ветеринария санитары: «Минтимер Шәриповичны яхшы җитәкче дип беләм. Әлегә ач-ялангачлар юк. Эшләү—зур бәхет. Ул безне шушы бәхеттән мәхрүм итмәсен. Президент белән бәйле өметләрем: милли мәсьәләдә гадел булсын, кеше эшсез калмасын, тәртипне ныгытсын».

ГАКЫЙЛ ГАЯЗОВ, машина-трактор паркы ремонтчысы: «Шәймиевның эшчәнлеген әлегәчә хуплап килдем. Менә Осиновода мәчет төзү артыннан йөрибез, халыктан акча җыя башлады инде, фабрика да булышырга вәгъдә итә. Кандидатны мин, әгәр Президент булып сайлана калса, Татарстанның тулы азатлыгы өчен көрәшер, дип ышанам. Шуңа өметләнеп кенә аңа тавыш бирәчәкмен».

ДАМИР ГЫЙМАДИЕВ, тракторчы - бульдозерчы: «Мин бу коллективта яңа кеше. Эшләүчегә акча әйбәт төшә, ай саен нормалап итен, йомыркасын биреп торалар. Хезмәттәшләремне хуплыйм мин. Әлбәттә, Шәймиевкә тавыш бирәчәкмен».

Билгеле, кошчылар күрсәткән кандидатның сайлау алды көрәше әле алда. Вакыт аз азын, әмма кошчылар үз үрнәкләренә башкалар да иярер, дип өметләнәләр.

**Б. АНТОНОВ.**

## Вакыйга булган урыннан хәбәр итәбез

# „Уянырга вакыт җитте...“

**19 май көнне Бөтенсоюз татар иҗтимагый үзәгенең Әлмәт бүлекчәсе шәһәр һәм регион җәмәгатьчелегенең кисәтү митингысын үткәрде. Митингта сүз 1991 елның 21 апрелендә Татарстанның дәүләт суверенлыгын тормышка ашыруга юнәлтелгән резолюциянең үтәлмәве турында барды. Союз килешүенә кулны тугыз союздаш республика вәкилләре генә кую хакындагы хәбәр бәйсезлекне парламент юлы белән яклау турындагы хыялларны юкка чыгарды.**

**Республикабызның алдынгы көчләре хәзер өметләрен Әлмәт төбәгенә, аның кара алтынына баглыйлар. Шунлыктан, әлеге кисәтү митингысының Әлмәттә үткәрелүе дә очраклы хәл түгел иде. Монда әлмәтлеләр белән бергә Казан, Чаллы, Түбән Кама, Лениногорск, Азнакай һәм башка район вәкилләре дә катнашты. Монда шулай ук Татарстан Югары Советы Рәисе М. Ш. Шәймиев, Министрлар Советы Рәисе М. Г. Сабиров, СССР, РСФСР, ТССР һәм җирле Советлар депутатлары, нефть һәм промышленность зонасы предприятиеләре һәм оешмалары җитәкчеләре дә чакырылган иде. Әмма бу иптәшләр халык белән очрашмауны мәгъкул күрделәр.**

**Әлеге митингта безнең газета корреспонденты да катнашты. Түбәндә сез әлеге митингтан репортаж белән танышырсыз.**

Митинг үзе сәгать 11дә генә башланырга тиеш булуга карамастан, иртәнге 9 дан ук шәһәрнең Нефтьчеләр сарае каршындагы мәйданда халык төркемнәре күренә иде. Кайсы бәйрәмчә, кайсы пөхтә генә эш киеменнән булган кешеләр Нефтьчеләр Сарае алдына эленгән күпсанлы өндәмә-лозунглар янына тукталып, сабыр гына сөйләшәләр. Шунда ук урнаштырылган фотостендта 21 апрельдә Әлмәттә булган манифестация һәм «Дуслык» нефтьүткәргече башланган урында килеп чыккан вакыйга сурәтләнгән иде. Янәшәдә генә Татарстанда РСФСР президенты сайлауга каршы имзалар җыялар. Төркем-төркем булып басып торган кешеләр телендә дә президент, депутат, мөстәкыйльлек дигән сүзләр әледән-әле кабатлана. Сәгать 10нарда шәһәр үзәгеннән шушы мәйданга юнәлгән демонстрантлар колоннасы күренде. Ярымайлы-йолдызлы байраклар күтәргән халык ташкыны мәйдандагы микрофоннар каршына ук үтте. Үзара күрешү-танышу, хәл-әхвәл сорашу башланды. Татар иҗтимагый үзәгенең Казан вәкилләре икән болар. Араларында татар зыялыларыннан Марат Мөлеков, Батулла, халык артисты Вафирә Гыйззәтуллина, шагыйрь Ркаил Зәйдулла, Башкортстаннан килгән татар шагыйре Айдар Хәлим һәм башкалар бар иде.

Митингны ачу алдыннан Әлмәт мәчете имамы Тәлгать хәзрәт фатиха сүзе әйтте. Аннан соң сүз Татар иҗтимагый үзәгенең Әлмәт бүлеге рәисе М. Зиннәтуллинга бирелде. Ул бүгенгә көндә нефтьчеләрнең эш хакларын бер ярым тапкырга күтәрүләрен, планнан тыш саткан нефтьнең 1 миллион тоннасын үзебезнең файдага тоту мөмкинлеге бирүләрен эшче халыкны тынычландыру өчен бер калҗа гына дип атады. Моның белән тынычланмаска чакырды. Чөнки май аенда гына да без республикадан читкә 240 мең тонна нефть озатабыз икән, 1992 елда исә нефть бездә 20 миллион тонна табылачак. Нефть үз җирендәге дәүләт карамагында булырга тиеш,—диде ул

**(Башы. Ахыры 2 нче биттә).**

# Халык депутатларының Октябрь район Советы президиумы КАРАРЫ

## РСФСР һәм ТССР Президентларын сайлау буенча участок сайлау комиссияләре составы турында

«РСФСР халык депутатларын сайлаулар турында»гы РСФСР Законының 24 статьясы һәм «Татарстан ССР халык депутатларын сайлаулар турында»гы Татарстан ССР Законының 24 статьясы нигезендә халык депутатларының Октябрь район Советы президиумы КАРАР бирә:

Участок сайлау комиссияләрен хезмәт коллективлары, җәмәгать оешмалары органнары, аларның башлангыч оешмалары, сайлаучыларның тору урыннары буенча җыелышлары тәкъдим иткән түбәндәге вәкилләре составында расларга:

**1. Яңа Иглай сайлау участогы**

Шәрипов Җәмил Касыйм улы, прораб, Сатдаров Вәгыйзь Вазыйх улы, баш экономист, Сатдарова Роза Фатыйх кызы, укытучы, Сатдарова Гөлкәй Нәҗип кызы, бухгалтер, Сатдарова Тәнзилә Рәшит кызы, укытучы, Мусина Наилә Тәлгать кызы, укытучы, Галимова Гөлсинә Нуриҗан кызы, бухгалтер, Гобәйдуллина Гүзәлия Баһдар кызы, халык депутатларының авыл Советы башкарма комитеты белгече, Хәйруллина Ләйсән Шәфигулла кызы, секретарь-машинистка, Галимова Исламия Әхәт кызы, халык депутатларының авыл Советы башкарма комитеты бухгалтеры, Гозәерова Фәридә Ризатдин кызы, хисапчы-кассир, —Яңа Иглай авылы сайлаучыларының гомуми җыелышыннан.

**2. Ключи сайлау участогы**

Бикиев Хәлил Җәмил улы, баш инженер, Алексеева Тамара Николаевна, пешекче, Летфуллина Гүзәл Мәсгут кызы, балалар бакчасы мөдире, Абдуллина Резидә Ильгиз кызы, урта мәктәп укытучысы, Усманов Сәгыйрь Сәгыйть улы, баш энергетик, Илалов Ринат Хатыйп улы, ветеринария врачы—Ключи поселогы сайлаучылары гомуми җыелышыннан.

**3. Югары Норлат сайлау участогы**

Әһлиуллин Ранас Шакир улы, укытучы, Фәхретдинов Сәлим Шакир улы, укытучы, Әхмәтсафина Рузалия Шәмгун кызы, китапханә мөдире, Хәйретдинов Илһам Ислам улы, укытучы, Сафиуллина Лилия Мәсгут кызы, балалар бакчасы мөдире,—урта мәктәп хезмәт коллективыннан, Әхмәтсафина Галия Фәткулла кызы, бухгалтер, Төхвәтуллина Роза Мәхмүт кызы, бухгалтер, Төхвәтуллина Гүзәлия Салих кызы, бухгалтер, Шәйхетдинов Рәис Хәмзә улы,—башлангыч партия оешмасы секретаре—мөгезле эре терлек симертү буенча хуҗалыкара берләшмә хезмәт коллективыннан.

**4. Түбән Норлат сайлау участогы**

Камалетдинов Минәхмәт Вәлиәхмәт улы, бухгалтер, Рәхмәтуллин Әнвәр Нәбиулла улы, бригадир, Галәветдинова Гөлсинә Сәлих кызы, бухгалтер, Мусин Камил Вәли улы, баш зоотехник, Тимербулатова Зәмзәмия Кәшиф кызы, китапханә мөдире, Мәүлетов Идрис Минехан улы, хуҗалык мөдире, Гыйрфанова Минзәмия Әсхәт кызы, сатучы, Әбҗәлимов Шәфик Шәмгун улы, шофер, Ильмухин Фердинанд Минәхмәт улы, авыл культура йорты мөдире,—«Кондырча» колхозы хезмәт коллективыннан.

**5. Кормыш сайлау участогы**

Ибраһимов Якуб Таһир улы, баш инженер, Кәлимуллин Йосыф Шакир улы, механик, —Хафизов исемендәге колхоз башлангыч партия оешмасыннан, Тәмаев Хәниф Харис улы, рәссам, Таймуллина Валентина Петровна, экономист, Ярукова Лидия Степановна, баш экономист, Хәлиуллин Мәҗидулла Нигъмәтулла улы, авыл культура йорты директоры, Тәмаева Гөлсинә Шәрифулла кызы—халык депутатларының авыл Советы башкарма комитеты бухгалтеры, Моратова Люция Таһир кызы, халык депутатларының авыл Советы башкарма комитеты хисапчы-кассиры, Шәйдуллина Нурсинә Сәлихҗан кызы, бухгалтер,—Хафизов исемендәге колхозның беренче бригадасы хезмәт коллективыннан.

**6. Чуваш Мәнҗесе сайлау участогы**

Ильичев Сергей Алексеевич, инженер төзүче, Сергеев Владимир Удаманович, клуб мөдире, Сергеев Виктор Александрович, колхозчы,—Хафизов исемендәге колхозның башлангыч партия оешмасыннан, Игнатьева Ирина Витальевна, бухгалтер, Сибулатов Сергей Дмитриевич, механизатор, Таймуллин Виталий Ильич, технолог, Исаева Эльмира Александровна, бухгалтер, —Хафизов исемендәге колхозның икенче бригадасы хезмәт коллективыннан, Имукова Галина Викторовна, мәктәп директоры, Парукова Арина Анатольевна, укытучы,—тулы булмаган урта мәктәп хезмәт коллективыннан.

**7. Аксумла сайлау участогы**

Улаев Леонид Семенович, колхозчы, Улаева Людмила Николаевна, башлангыч мәктәп укытучысы, —«Большевик» колхозының 2 нче бригадасы хезмәт коллективыннан, Пайдуганова Валентина Александровна, китапханә мөдире, Туймешева Валентина Ивановна, халык депутатларының авыл Советы башкарма комитеты белгече, Паруков Александр Ильич, бригадир ярдәмчесе, Парукова Валентина Геннадьевна, бухгалтер,—1 нче бригада хезмәт коллективыннан, Ендиряков Геннадий Михайлович, укытучы, Туймешева Лидия Ильинична, укытучы, — тулы булмаган урта мәктәп хезмәт коллективыннан, Кадяшева Галина Константиновна, эшче,—җиләк-җимеш питомнигы хезмәт коллективыннан.

**8. Әхмәт сайлау участогы**

Җәппаров Рәхимҗан Гәрәй улы, хисапчы, Әхмәтова Әминә Йөземхан кызы, укытучы, Вәлиуллин Рафаэль Таһир улы, товарлыклы-сөтчелек фермасы мөдире,—«Москва» колхозы хезмәт коллективыннан, Галимов Рафик Равил улы, шофер, Галәветдинов Касыйм Минкәрим улы, клуб мөдире,—Әхмәт авылы сайлаучылары җыелышыннан, Сәгыйров Габделхан Нурхамит улы, тракторчы, Хәбибуллин Миннехан Мингалим улы, тракторчы,—«Москва» колхозы башлангыч партия оешмасыннан.

**9. Якушкино сайлау участогы**

Алякимов Николай Мадьянович, профсоюз комитеты председателе, Перепелкин Александр Исаевич, техник-төзүче, Иштуллина Жозефина Ивановна, ветеринария врачы, Евдокимова Юлия Николаевна, урта мәктәп директоры, Волкова Лена Дмитриевна, китапханә мөдире, Артюшкин Петр Михайлович, киномеханик, Ларионов Олег Николаевич, товарлыклы-сөтчелек фермасы мөдире, Яковлева Галина Петровна, саклык кассасы контролеры, Алякимов Николай Дмитриевич, авыл культура йорты рәссамы, —«Заря» колхозы хезмәт коллективыннан.

**10. Абрыскино сайлау участогы**

Егоров Валентин Филиппович, техника куркынычсызлыгы инспекторы, Андреев Петр Тимофеевич, тулы булмаган урта мәктәп укытучысы, Архипова Светлана Георгиевна, укытучы, Михайлова Зоя Васильевна, склад мөдире, Ефимова Зоя Николаевна, техничка, Питуганова Мария Федоровна, бухгалтер, Сандрюхин Юрий Семенович, электрик,—«Родина» колхозы хезмәт коллективыннан.

**11. Салдакай сайлау участогы**

Азяков Михаил Улаевич, хуҗалык мөдире, Илюхин Петр Иванович, экономист, Пантерина Галина Константиновна, тулы булмаган урта мәктәп укытучысы, Хәмидуллин Хасибулла Хабибулла улы, укытучы, Петров Валерий Трифонович, укытучы, Юхмальчина Нина Васильевна, фельдшер, Васильев Олег Тихонович, тракторчы, Васюткин Иван Матвеевич, кочегар, Рудина Ирина Васильевна, кассир,—«Родина» колхозы хезмәт коллективыннан.

**12. Бикүле сайлау участогы**

Шәкуров Исмәгыйль Әхмәт улы, укытучы, Әһлетдинов Мансур Госман улы, укытучы,—урта мәктәп коллективыннан, Әхмәтова Нурсинә Шәрифулла кызы, авыл Советы бухгалтеры, Шәйхетдинов Рөстәм Нуриҗан улы, ветеринария врачы, Миннеголов Ирек Солухан улы, техник-төзүче, Ибраһимова Асия Вәлимөхәммәт кызы, художество җитәкчесе, Хаммәтова Роза Госман кызы, ВУС начальнигы, Шәйхетдинова Рушания Фатыйх кызы, кассир, Мингалимов Фәрит Хәлил улы, шофер, —Муса Җәлил исемендәге колхоз хезмәт коллективыннан.

**13. Кәкре Атау сайлау участогы**

Хәйруллин Хәлиулла Нәбиулла улы, укытучы, Сабирова Резидә Сәлим кызы, укытучы, Зәйнетдинов Вахит Касыйм улы, укытучы,—урта мәктәп коллективыннан, Гыйләҗева Хәмдия Хәмзә кызы, бухгалтер, Кыямов Марат Мөнир улы, КПССның башлангыч оешмасы секретаре, Хәсәнгатина Зәйнәп Мәхмүт кызы, китапханәче, Сираҗетдинов Рифкать Исламгәрәй улы, бригадир, Сибгатуллин Хәйдәр Нәбиулла улы, экономист, Хәлиуллин Дамир Сәмигулла улы, шофер,—«Чирмешән» колхозы хезмәт коллективыннан.

**14. Илюткино сайлау участогы**

Михайлов Виталий Леонтьевич, уку-укыту эшләре мөдире, Сергеева Галина Зәкиевна, укытучы, урта мәктәп коллективыннан, Ерепов Илья Иванович, кочегар, Николаев Владимир Васильевич, шофер, Фомина Зинаида Ивановна, клуб мөдире, Чернов Валерий Максимович, механизатор, Абрамова Антонина Петровна, китапханәче, — «Москва» колхозы хезмәт коллективыннан.

**15. Биләр Озеро сайлау участогы**

Матросов Август Иванович, укытучы,—«Путь к коммунизму» колхозы башлангыч партия оешмасыннан, Садыйков Йосыф Хатыйп улы, мәктәп директоры, Граф Алевтина Александровна, укытучы, —урта мәктәп хезмәт коллективыннан, Лыкова Мария Игнатьевна, экономист, Албутов Анатолий Гаврилович, шофер, Севастьянова Марина Геннадьевна, секретарь-машинистка, Лыкова Татьяна Васильевна, кадрлар бүлеге инспекторы, Кисеньков Сергей Геннадьевич, шофер,— колхозның икенче бригадасы хезмәт коллективыннан, Семенова Анна Наумовна, ферма мөдире,—колхозның икенче номерлы товарлыклы-сөтчелек фермасы хезмәт коллективыннан.

**16. Гәйтән сайлау участогы**

Авдеева Валентина Валериановна, укытучы, Яндукова Светлана Михайловна, пешекче,—тулы булмаган урта мәктәп хезмәт коллективыннан, Михедеров Иван Дмитриевич, колхозчы, Ишмуллин Валерий Владимирович, тракторчы, Авдеева Валентина Марковна, сыер савучы, Глушкин Гурий Васильевич, киномеханик, Авдеев Сергей Владимирович, колхозчы,—«Путь к коммунизму» колхозының беренче бригадасы хезмәт коллективыннан, Ярункина Ольга Якимовна, китапханә мөдире,— колхоз башлангыч партия оешмасыннан, Глушкин Валерий Владимирович, тракторчы, —ВЛКСМның колхоз башлангыч оешмасыннан.

**17. Биккол сайлау участогы**

Мөбәрәкшин Илгиз Нургаян улы, мәктәп директоры, Әһлиуллина Исламия Миннехан кызы, укытучы, Сираҗева Гөлфия Әнвәр кызы, укытучы, Кәримова Гүзәл Вил кызы, укытучы,—Биккол урта мәктәбе хезмәт коллективыннан, Нуриҗанов Мирзаҗан Таһирҗан улы, кассир, Вәлиәхмәтов Азат Гали улы, китапханә мөдире, Миннеголов Зәки Миннехан улы, пенсионер, Хатыйпова Раилә Тәлгать кызы, бухгалтер, Мортазин Таһир Талип улы, клуб мөдире,—«Таң» колхозы хезмәт коллективыннан.

**18. Фома сайлау участогы**

Шәрифуллина Халифә Әхәт кызы, китапханә мөдире, Вәлиуллин Әхәт Әнвәр улы, авыл культура йорты директоры, Галиуллина Равидә Сәлим кызы, сатучы, Закиров Нурислам Галимҗан улы, колхозчы, Ситдыйкова Әлфия Хөснулла кызы, элемтә узелы операторы,—«Игенче» колхозы хезмәт коллективыннан, Вәлиәхмәтова Розалия Хәсәнгата кызы, авыл Советы башкарма комитеты баш бухгалтеры,—халык депутатларының авыл Советы башкарма комитеты аппараты хезмәт коллективыннан, Хафизова Нәгыймә Нургали кызы, укытучы, Мирзагалимова Нурзия Марат кызы, балалар бакчасы мөдире, Мәхмүтова Фәридә Дамир кызы, балалар бакчасы тәрбиячесе, — урта мәктәп хезмәт коллективыннан.

**19. Зирекле сайлау участогы**

Хәмзин Рәшит Рафик улы, ферма мөдире, —товарлыклы-сөтчелек фермасы хезмәт коллективыннан. Галимов Тәлгать Харис улы, механизатор, Миннеголов Рифкать Әбделхан улы, тракторчы, Кәбирова Гөлкәй Шәриф кызы, кассир, Фәссахова Ралия Гариф кызы, бухгалтер, —«Үрнәк» колхозы хезмәт коллективыннан, Мостафина Гөлүсә Касыйм кызы, китапханә мөдире,—хатын-кызлар союзы башлангыч оешмасыннан, Хәммәдиева Розалия Әсхәт кызы, укытучы,—урта мәктәп хезмәт коллективыннан.

**20. Чулпан сайлау участогы**

Мотыйгуллин Ирек Сәлим улы, укытучы, Хафизуллина Флюра Әхмәдулла кызы, укытучы,—урта мәктәп хезмәт коллективыннан, Фәйзуллин Рәшит Абдрахман улы, агроном, —КПССның колхоз башлангыч оешмасыннан, Хәлимова Рузалия Вәгыйзь кызы, кадрлар буенча инспектор, —«40 лет Победы» колхозы хезмәт коллективыннан, Харитонов Анатолий Федорович, пенсионер, Мортазина Әлфия Таһир кызы, бухгалтер, халык депутатларының авыл Советы башкарма комитеты аппараты хезмәт коллективыннан, Вәлиәхмәтов Рөстәм Солтан улы, тракторчы, —трактор паркы хезмәт коллективыннан, Кубарева Надежда Леонидовна, күзәтүче,—метеостанция хезмәт коллективыннан, Кәримова Гөлшат Шакир кызы, шәфкать туташы,—участок больницасы хезмәт коллективыннан.

**21. Заречный сайлау участогы**

Александров Николай Михайлович, профком председателе, Усманова Әлфия Хәйдәр кызы, бухгалтер,—урман промышленносте хуҗалыгы идарәсе аппараты хезмәт коллективыннан, Гыйльметдинов Азат Гомәр улы, аккумуляторчы, Волков Василий Дмитриевич, хуҗалык мөдире, Мирзаҗанов Булат Ислам улы, начальник, Чулпан урман пункты хезмәт коллективыннан, Низамиева Галина Федоровна, сатучы,—урман промышленносте хуҗалыгы профсоюз оешмасыннан, Ильмухина Ирина Владимировна, тәрбияче, —Заречный башлангыч мәктәп хезмәт коллективыннан, Лебедева Зоя Васильевна, медпункт санитаркасы, —хатын-кызлар союзы башлангыч оешмасыннан.

(Ахыры киләсе санда).

